ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:
а) алтынчы абзацта “$1^2$ өлешендә” сүзләрен “5 өлешендә” сүзләренә алмаштырырга;
б) җиденче абзацта “3 статьясындагы 2 өлешендә” сүзләрен “3 статьясындагы $1^1$ һәм 2 өлешләрендә” сүзләренә алмаштырырга;
в) сигезенче абзацта “өстенлекле” сүзен төшереп калдырырга, “25 проценттан” сүзләрен “биш проценттан” сүзләренә алмаштырырга;

г) унынчы абзацта “рәсми статистик мәгълүматны формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле” сүзләрен “Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыручы” сүзләренә алмаштырырга;

д) унбишенче абзацта “шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен” сүзләреннән соң “төзелеш проектының җыелма тупланма исемлеген” сүзләрен өстәргә;

е) унтугызынчы абзацта “бетерү турында” сүзләреннән соң “, шул исәптән “Төзүчеләрнең бөлгенлеге (банкротлыгы) вакытында өлешле төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясындагы $5^2$ өлешенең 1 һәм 2 пунктлары нигезендә “Өлешле төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды” гавами-хокукый компаниясеннән хәбәрнамә алынган очракта,” сүзләрен өстәргә;

ж) утыз бишенче абзацта “5 өлешендә” сүзләрен “5 һәм $6^2$ өлешләрендә” сүзләренә алмаштырырга;

з) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“хокукларны теркәү органына Федераль законның 3 статьясындагы $2^6$ өлешендә каралган хәбәрнамәне җибәрү.”;

2) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ статья өстәргә:

“$7^1$ статья. **Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе**

Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) оештыруга һәм үткәрүгә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан куелган таләпләрне истә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан башкарыла.”.

**2 статья**

Әлеге Закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 08 декабрь
№ 96-ТРЗ